ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» 140-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов, В.Н. Миронченко тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» 140-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 503-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов,
В.Н. Миронченко
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш), «ала карга» сүзләрен «ала карга, бүре белән эт кушылмасы (табигый яшәү тирәлеге аучылык җирләре булган хайванның бер төре)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 июнендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән имезүчеләрне һәм кошларны аучылык ресурсларына кертү рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясындагы 3 өлеше белән Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык ресурсларына ала карга кертелгән. Закон проектында күрсәтелгән пунктка табигый яшәү тирәлеге аучылык җирләре булган хайванның бер төре булып торучы бүре белән эт кушылмасын өстәү тәкъдим ителә.

Ел саен республиканың аучылык җирләрендә бүре белән эт кушылмасы күзәтелә, алар өерләргә туплана һәм гражданнар өчен дә, хайваннар дөньясы объектлары өчен дә җитди куркыныч тудыра.

Республикада алар тарафыннан кыргый хайваннар популяцияләренә зыян китерелгән очраклар бар. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының район белгечләре һәм аучылар даими рәвештә аучылык җирләрендә әлеге ерткычлар тарафыннан куып китерелгән һәм буып үтерелгән кыр кәҗәләре үләксәләрен табалар, бу бигрәк тә еш кына кышын тирән итеп кар басып киткән шартларда була. Китерелгән зыянның бәясе 3 млн сумга якын тәшкил итә.

Бүре белән эт кушылмасы котыру чирен таратучылар булып тора. Кеше алдында курку хисе кичермәгәнлектән, алар торак пунктларга якын килергә һәм йорт хайваннары һәм кеше белән элемтәгә керергә мөмкин.

2025 елның 11 ае эчендә генә республикада 22 котыру чире очрагы ачыкланган.

Законны кабул итү күрсәтелгән кыргый хайваннар гамәлләреннән экологик зыянны киметүгә ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.